ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**29.04.2019** Казан ш. **№ 87**

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2016 елның 13 июлендәге 168 номерлы боерыгы белән расланган Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 октябрендәге 382-ФЗ номерлы федераль закон чыгарылуга бәйле рәвештә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) 2016 елның 13 июлендәге 168 номерлы боерыгы белән расланган Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Тарифлар

буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта икенче абзацтагы «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы» сүзләрен төшереп калдырырга;

Тәртипкә 1 нче кушымтада «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Кадрлар бүлеге башлыгына (Т.А.Толстая) Дәүләт комитеты дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга.

3. Бу боерык аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Дәүләт комитеты рәисе урынбасары Д.А.Симкачевка йөкләргә.

Рәис в.б. А.Л.Штром